РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 02 2021 г. № 70

Ютазы муниципаль районында торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы №1 карары белән расланган Башкарма комитет турында нигезләмәгә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл торак пунктларында, Урыссу шәһәр тибындагы поселогында яшәүче һәм эшләүче муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта, торак урыннары, җылылык һәм электр энергиясе өчен түләү чыгымнарының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү нормативлары чикләрендә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә компенсация түләнә. Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасы авыл җирендә, шәһәр тибындагы Урыссу

поселогында урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләрендә 10 елдан да ким булмаган чорда эшләсәләр һәм шунда яшәсәләр, пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә сакланып кала.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Авыл җирендә, Урыссу шәһәр тибындагы поселогында эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарына торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында" 2007 ел, 28 март, №51 карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Р. М. Якупов

2-74-14